КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 декабрь г.Казань № 1315

2021 елда шәһәр пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы муниципаль автотранспорт предприятиеләренең алынып бетмәгән керемнәрен каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләренең 50 процентын финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елда шәһәр пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы муниципаль автотранспорт предприятиеләренең алынып бетмәгән керемнәрен каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләренең 50 процентын финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 29 декабрь, 1315 нче
карары белән расланды

2021 елда шәһәр пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы муниципаль автотранспорт предприятиеләренең алынып бетмәгән керемнәрен каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләренең 50 процентын финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип 2021 елда шәһәр пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы муниципаль автотранспорт предприятиеләренең алынып бетмәгән керемнәрен каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләренең 50 процентын финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар 2021 елда бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен акча белән баш эш итүче буларак Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлек бюджетына бирү шартлары:

шәһәр пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы муниципаль автотранспорт предприятиеләренең алынып бетмәгән керемнәрен каплауга субсидияләр бирү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый акт булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен җитәрлек күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен кертеп) булу;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлек йөкләмәсе күздә тотыла торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

4. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) – 2021 елда пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда «даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты» күрсәткече ярдәмендә бәяләнә торган транспорт хезмәте күрсәтү ышанычлылыгы, аның күрсәткече ≥ 0,7 булырга тиеш.

2021 елга даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты ($К_{расп}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К_{расп} = \frac{\sum Q_{фактрейс}}{\sum Q_{рейсрасп}} \geq 0{,}7,$$

монда:

$Q_{фактрейс}$ – 2021 елга автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда башкарылган рейсларның факттагы саны;

$Q_{рейсрасп}$ – 2021 елга автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда расписаниедә билгеләнгән рейслар саны.

5. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлек Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗның финанс-икътисадый нигезләве теркәлгән, ирекле формада язылган башка бюджетара трансферт бирү турында заявка (алга таба – заявка);

муниципаль берәмлек бюджетында бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен үз эченә ала торган чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы карарыннан өземтә;

бу Тәртипнең 3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль хокукый акт күчермәсен.

6. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында яки башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәмәү;

бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

бу Тәртипнең 5 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлеккә заявка теркәлгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә җибәрелә.

9. Муниципаль район бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

10. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык белән муниципаль берәмлек арасында Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

11. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең зурлыгы;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

муниципаль берәмлек бюджетының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе турында хисаплар бирү сроклары һәм формалары;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең билгеләнгән зурлыгына ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

12. Бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка бюджетара трансфертлар бирүгә бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты белән билгеләнә.

13. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.

14. Муниципаль берәмлек 2022 елның 1 февраленә кадәр килешүдә каралган тәртиптә һәм форма буенча муниципаль район бюджетының финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән зурлыгы турында Министрлыкка хисаплар тапшыра.

15. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткече зурлыгын 2021 ел йомгаклары буенча фактта ирешелгән нәтиҗәлелек күрсәткече зурлыгы белән чагыштыру аша гамәлгә ашырыла.

16. Муниципаль берәмлек бу Тәртипнең 14 пункты нигезендә тапшырыла

торган хисапларның дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

17. 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2022 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә түләтелергә тиеш.

18. Әгәр 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган һәм әлеге бозулар башка бюджетара трансфертлар бирелгән елда бу Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән хисаплар бирү датасына кадәрге срокта бетерелмәгән булса, башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның 1 мартына кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{кайтару}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$V_{кайтару} = (P \times D) \times 0{,}1,$$

монда:

P – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

D – башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

19. Муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләмен хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләмендә исәпләгәндә 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган күләме исәпкә алынмый.

20. Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$D = 1 - \frac{T}{0{,}7},$$

монда:

T – хисап чорына нәтиҗәлелек күрсәткеченең фактта ирешелгән зурлыгы;

0,7 – нәтиҗәлелек күрсәткеченең план буенча зурлыгы.

21. Муниципаль район тарафыннан аны бирү шартлары бозылган очракта, шул исәптән муниципаль район тарафыннан бу Тәртипнең 17 һәм 18 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

22. Бу Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларны максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту законнар нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.